Республика Татарстан
Палата имущественных и земельных отношений
Заинского муниципального района

ул.Автозаводская, д.1А, г.Заинск,
Республика Татарстан, 423520
тел.2-80-31, 2-80-34
факс: 8(85558)2-80-33

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының милек
һәм җир мөнәсәбәтләре
Палатасы

Автозавод урамы, 1А йорт,
Зәй шәһәре Татарстан
Республикасы, 423520
тел.2-80-31, 2-80-34
факс: 8(85558)2-80-33

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«13» 08 2021г. № 622П

**Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының 2019 елның 06 августындагы 541П номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип тану турында**

В"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

**боерык бирә:**

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулашулар үткәрми генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 06 августындагы 541П номерлы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Боерык рәсми төстә басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы О.Ф. Миңнехуҗинага йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р.Шәйхиев**

Юрисконсульт